**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 13 февралендәге 433 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10376 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль милкен бушлай файдалануга бирү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан шәһәре милке белән идарә итү һәм эш итү системасын камилләштерү, аннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10376 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль милеген бушлай файдалануга бирү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 2 июнендәге 2278 номерлы, 2018 елның 20 августындагы 4598 номерлы, 2022 елның 20 маендагы 1471 номерлы, 2024 елның 15 июлендәге 2986 номерлы, 2025 елның 12 ноябрендәге 3963 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.4. Казан шәһәре Башкарма комитеты органнарына, муниципаль учреждениеләргә (бюджет, автоном, казна), муниципаль унитар предприятиеләргә оператив идарә итү, хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән муниципаль милек Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарына, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнарына, муниципаль учреждениеләргә (бюджет, автоном, казна), шулай ук Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы медицина оешмаларының бердәм реестрына кертелгән дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә (мәгариф оешмаларында укыту һәм тәрбияләү чорында 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарга беренчел медик-санитария ярдәме

күрсәтү максатларында) бушлай файдалануга бирелгән очракта, бушлай файдалану шартнамәсендә яклар килешүе буенча ссуда алучыны бушлай файдалануга бирелә торган муниципаль милекне тиешле хәлдә тоту, муниципаль милекне карап тоту, әлеге милекне, йорт яны территориясен һәм төзекләндерү объектларын тиешле хәлдә карап тоту (капиталь һәм агымдагы ремонт, теркәү, саклау, коммуналь түләүләр, махсус – техник, санитария һ.б. – карап тоту, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, дәүләт янгын күзәтчелеге органнары күрсәтмәләрен үтәү, шулай ук милеккә салым түләү һәм җир кишәрлегеннән файдаланган өчен түләү) буенча финанс чыгымнарын күтәрү бурычыннан азат итү рөхсәт ителә»;

1.2. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына (Р.Г.Галәветдинов) – Казан шәһәре милек казнасы составында булган милеккә карата, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнарына (Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетыннан тыш), муниципаль учреждениеләргә (бюджет, автоном, казна), муниципаль унитар предприятиеләргә – оператив идарә итү, хуҗалык алып бару хокукында үзләренә беркетелгән милеккә карата:

3.1. бушлай куллануга бирелгән муниципаль милекнең исәбен алып барырга;

3.2. төзелгән килешүләр нигезендә бушлай куллануга бирелгән муниципаль милекне куллануны контрольдә тотарга һәм килешү шартлары бозылган очракта, килешүләрне өзгәнчегә кадәр тиешле чаралар күрергә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**